СОВЕТ НИЖНЕШАНДЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Школьная, д.1, с. Зюри,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422153

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТҮБӘН ШҮЛӘҢГЕР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Мәктәп ур., 1 нче йорт, Җөри авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422153

тел.(факс): (85563) 3-87-31; e-mail: Nsnd.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
от 20 июня 2023 г.

Карар
№ 2-24

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл
җирлеге муниципаль милкенә карата
концессион килешү төзү турында
карар кабул итүгә ризалык бирү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Түбән Шүләңгер авыл җирлеге башкарма комитетына коммуналь инфраструктура һәм башка коммуналь хуҗалык объектларына, шул исәптән су белән тәэмин итү объектларына, үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системаларына, мондый системаларның аерым объектларына хезмәт күрсәтүгә концессион килешү төзү турында карар кабул итүгә ризалык бирергә.

2. 1 нче кушымтада бирелгән күчемсез мөлкәтне концессион килешү объектлары итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар халыкка җиткерелгән (басылып чыккан) көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районыны Түбән Шүләңгер авыл җирлеге башлыгы Е.М.Михайловага йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Шүләңгер авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе /Е.М.Михайлова /

1 нче кушымта

## Концессион килешү объектлары, шул исәптән техник-икътисадый күрсәткечләре, техник халәте, хезмәт срогы

| № п/п | объектның исеме | Кадастр номеры | урнашу урыны адресы ( торак пункт/ур.) | Техник параметрлар (мәйдан/диаметр/биеклек/озынлыгы һ.б.) | Гамәлгә керү елы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Җөри авылы су үткәргеч челтәре | 16:26:000000:4446 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Җөри авылы | су үткәргеч челтәре 4148 м. п/э D - 150 | 1981 |
| 2 | Җөри авылы Суүтем башнясы | Хокук билгеләүче документлар рәсмиләштерү стадиясендә | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Җөри авылы | Суүтем башнясы тирәнлек70 м. металлдан | 1981 |
| 3 | Комаровка авылы су үткәргеч челтәре | 16:26:000000:4445 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Комаровка авылы | су үткәргеч челтәре 1725 м. п/э D - 110 | 1985 |
| 4 | Комаровка авылы Суүтем башнясы | Хокук билгеләүче документлар рәсмиләштерү стадиясендә | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Комаровка авылы | Суүтем башнясы тирәнлек 70 м. металлдан | 1985 |
| 5 | Түбән Шүләңгер авылы су үткәргеч челтәре | 16:26:000000:4444 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Түбән Шүләңгер авылы | су үткәргеч челтәре , озынлыгы 2074 м. п/э D - 110 | 1982 |
| 6 | Түбән Шүләңгер авылы Суүтем башнясы | Хокук билгеләүче документлар рәсмиләштерү стадиясендә | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Түбән Шүләңгер авылы | Суэтем башнясы тирәнлек 70 м. металлдан | 1982 |
| 7 | Ылыя авылы су үткәргеч челтәре | 16:26:000000:4195 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Ылыя авылы | су үткәргеч челтәре , озынлыгы 2522 м. п/э D - 110 | 2013 |
| 8 | Ылыя авылы Суүтем башнясы | Хокук билгеләүче документлар рәсмиләштерү стадиясендә | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Ылыя авылы | Биеклеге 12м. металдан | 2013 |